КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 30 декабрь г.Казань № 1346

Татарстан Республикасында граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләре бирелгән җирле үзидарә органнарында тантаналы шартларда никахлашуны дәүләт теркәвенә алу тәртибен раслау турында

«Граждан хәле актлары турында» 1997 елның 15 ноябрендәге 143-ФЗ номерлы Федераль законның 27 статьясындагы 5 пункты, Татарстан Республикасы Гаилә кодексының 8 статьясындагы $4^1$ өлеше, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарына граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен бирү турында» 2005 елның 30 декабрендәге 146-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Татарстан Республикасында граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләре бирелгән җирле үзидарә органнарында тантаналы шартларда никахлашуны дәүләт теркәвенә алу тәртибен расларга.
2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Граждан хәле актларын теркәү идарәсенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 30 декабрь, 1346 нчы
карары белән расланды

Татарстан Республикасында граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләре бирелгән җирле үзидарә органнарында тантаналы шартларда никахлашуны дәүләт теркәвенә алу тәртибе

1. Шәһәр округларының һәм муниципаль районнарның граждан хәле актларын теркәү органнарында, Татарстан Республикасында граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләре бирелгән шәһәр һәм авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнарында (алга таба – ГХАТ органнары) тантаналы шартларда никахлашуны дәүләт теркәвенә алу Россия Федерациясе Гаилә кодексы, «Граждан хәле актлары турында» 1997 елның 15 ноябрендәге 143-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – Федераль закон), Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының 2018 елның 28 декабрендәге 307 номерлы боерыгы белән расланган Россия Федерациясе территориясендә граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алуны гамәлгә ашыручы органнар тарафыннан граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты (алга таба – Административ регламент), Татарстан Республикасы Гаилә кодексы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарына граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен бирү турында» 2005 елның 30 декабрендәге 146-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм бу Тәртип нигезендә башкарыла.

2. Тантаналы шартларда никахлашуны дәүләт теркәвенә алу никахлашучы затлар теләге белән Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә башкарыла.

3. Тантаналы шартларда никахлашуны дәүләт теркәвенә алу датасы һәм вакыты, никахлашучы затлар белән килештереп, әлеге никахлашу ГХАТ органнарының боеру характерындагы актларында билгеләнгән аларның эш графигы нигезендә башка дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә комачауламау шарты белән, Федераль закон һәм Административ регламент таләпләре нигезендә билгеләнә.

4. Тантаналы шартларда никахлашуны дәүләт теркәвенә алу тантанасы, Федераль законда һәм Административ регламентта билгеләнгән таләпләрне исәпкә алып, ГХАТ органнарының махсус бизәлгән урыннарында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Никахлашуны дәүләт теркәвенә алу өчен тарихи-мәдәни мирас объектларыннан файдалану турында» 2010 ел, 3 июнь, 431 нче карарында, җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актларында исемлеге билгеләнгән башка урыннарда үткәрелә.

5. Тантаналы шартларда никахлашуны дәүләт теркәвенә алу түбәндәге мәҗбүри тантана чараларыннан тора:

никахлашучы затларны һәм аларның кунакларын каршы алу һәм аларны тантаналы теркәү залына чакыру;

техник чараларны кулланып, музыка белән алып бару;

тантаналы сөйләм;

никахлашучы затларда никахлашуга ризалыгын раслау;

никахлашучы затларның никахлашуы турында акт язуын уку һәм аңа имзаларын кую;

никахлашкан затларны ир һәм хатын дип игълан итү;

туй балдаклары алмашу (теләк буенча);

никахлашу турында документ тапшыру;

никахлашкан затларны котлау.

6. Тантаналы шартларда никахлашуны дәүләт теркәвенә алу тантанасын үткәргән өчен дәүләт пошлинасы түләнә, аны түләү (түләүдән азат итү) күләме һәм тәртибе салымнар һәм җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары белән билгеләнә.

7. ГХАТ органнары хезмәткәрләре өстәмә хезмәтләр күрсәтми һәм мондый хезмәтләр башка затлар тарафыннан күрсәтелгән өчен җавап бирми.

8. ГХАТ органнарының боеру характерындагы актларында тантаналы шартларда никахлашуны дәүләт теркәвенә алу тантанасы кагыйдәләре һәм аларда катнашучыларның тотышы тәртибе билгеләнә.

9. Никахлашучы затлар тантаналы шартларда никахлашуны дәүләт теркәвенә алу тантанасында катнашу өчен кунаклар чакырырга мөмкин. Чакырыла торган затлар саны тантаналы теркәү залының сыйдырышлылыгы белән чикләнә һәм никахлашучы башка затларның хокукларын бозмаска тиеш.

10. ГХАТ органы хезмәткәре никахлашучы затларга алар чакырачак кунакларның рөхсәт ителә торган максималь саны турында хәбәр итәргә тиеш. Мондый хәбәрнамә никахлашучы затлардан язма рәвештә никахлашу турында уртак гариза шәхсән кабул ителгәндә, ә әлеге гариза «Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы һәм Татарстан Республикасының дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша электрон документ рәвешендә тапшырылган очракта – әлеге гариза тапшырылган көннән өч эш көненнән дә соңга калмыйча, электрон формада яки гаризада күрсәтелгән телефон номеры буенча бирелә.

Татарстан Республикасы территориясендә (Татарстан Республикасының тиешле муниципаль районы территориясендә) югары әзерлек режимы, гадәттән тыш хәл режимы кертелүгә бәйле рәвештә билгеләнгән чикләү чаралары гамәлдә булган чорда, никахлашучы һәм тантаналы шартларда никахлашырга теләк белдергән затларга ГХАТ органнары хезмәткәрләре тарафыннан тантаналы шартларда никахлашуны дәүләт теркәвенә алу һәм әлеге чикләүләрне исәпкә алып билгеләнә торган тантана үткәрү шартлары турында бу пунктның беренче абзацында билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда хәбәр ителә.

11. Никахлашучы затларга һәм аларның кунакларына тантаналы шартларда никахлашуны дәүләт теркәвенә алу урыны буенча ГХАТ органына никахлашуны дәүләт теркәвенә алу өчен билгеләнгән вакытка кадәр 20 минут кала килергә кирәк.

12. Тантаналы шартларда никахлашуны дәүләт теркәвенә алу график нигезендә билгеләнгән вакытта үткәрелә һәм анда катнашучыларның соңга калуы аркасында кичектерелми.

___